| | |
|---|---|
| **ГЛАВА**<br>**Бимского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Бима авыл җирлеге**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.10.2019 Бима авылы № 5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу буенча Комиссия төзү турында

«2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте комиссиясен төзү турында» 29.09.2017, №1185 РФ Хөкүмәте Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча комиссия төзү турында» 2019 ел, 15 август, 682 нче карары, «Татарстан Республикасы «Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча комиссия төзү турында» 2019 ел, 26 сентябрь, 81 нче карары нигезендә һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча җирле үзидарә органнары белән килештерелгән гамәлләрне координацияләү һәм тәэмин итү максатларында, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елның 1 гыйнварына кадәр Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча комиссия төзергә.

2. Кушымтадагыларны расларга:

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү комиссиясе турында НИГЕЗЛӘМӘ (1 нче кушымта);

- Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Бима авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү комиссиясе составы (2 нче кушымта).

3. Халык санын алуны тулысынча тәэмин итү максатларында түбәндәге беренчел чараларның үтәлешен тәэмин итәргә:

3.1. 2019 елның 1 ноябренә кадәр:

- һәр торак пунктта адреслы хуҗалыкның торышын тоташ тикшерүне оештырырга һәм җитмәгән урыннарны урнаштыру һәм урам, йорт, фатир номер билгеләрен алыштыру буенча эшләрне төгәлләргә.